ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 22 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 75 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2026, № 2 (I өлеш), № 16 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 32 статьяга түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:
«9. Дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләре индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт яны җир кишәрлеге), үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен әлеге Кодексның $32^3$ статьясында билгеләнгән тәртиптә җир кишәрлеген бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, Россия Федерациясе дәүләт бүләкләү системасын камилләштерүнең кайбер мәсьәләләре турында Россия Федерациясе Президенты указы нигезендә «Герой ана» исеменә

лаек булган хатын-кызларга (алга таба – «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызлар) милеккә түләүсез бирелә.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $32^3$ статья өстәргә:

«$32^3$ статья. **«Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызларга җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү тәртибе**

1. Җир кишәрлеген милеккә түләүсез алу максатларында «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кыз җир кишәрлеген бирү турында гариза белән үзе даими яши торган территория кергән муниципаль берәмлекнең вәкаләтле җирле үзидарә органына мөрәҗәгать итә.

2. Җир кишәрлеген бирү турында гаризада «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәү урыны, почта адресы, элемтә өчен телефон номеры һәм (яисә) электрон почта адресы, шулай ук җир кишәрлегеннән файдалануның максаты күрсәтелә.

3. Җир кишәрлеген бирү турында гариза белән бергә түбәндәгеләр тапшырыла:

1) мөрәҗәгать итүченең паспорты;

2) «Герой ана» исеме бирелүне раслый торган документ;

3) мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәвен билгеләү турында суд карары (мөрәҗәгать итүченең паспортында җир кишәрлеген бирү турында гариза биргән көнгә кадәр биш ел дәвамында Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлү турында тамга булмаган очракта);

4) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ (вәкил мөрәҗәгать иткән очракта).

4. Вәкаләтле җирле үзидарә органы җир кишәрлекләрен милеккә түләүсез бирү максатларында «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызларның исәбен (алга таба – исәп) алып баруны гамәлгә ашыра.

5. Исәпкә кую турында яисә баш тарту өчен нигез күрсәтелгән исәпкә куюдан баш тарту турында карар вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан җир кишәрлеген бирү турында гариза теркәлгән көннән алып 20 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

6. Исәпкә куюдан баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) әлеге статьяның 3 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмау;

2) тапшырылган документларда җир кишәрлеген әлеге Кодексның 32 статьясындагы 9 пункты нигезендә милеккә түләүсез бирү хокукын раслый торган белешмәләрнең булмавы.

7. Исәпкә кую яисә исәпкә куюдан баш тарту турында карар «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызга кабул ителгән көненнән алып җиде көн эчендә тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән җибәрелә йә аңа имза куйдырып тапшырыла.

8. Исәпкә кую турында карар кабул ителгән очракта, «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кыз турында белешмәләр «Герой ана» исеменә лаек булган, җир

кишәрлеген милеккә түләүсез алу хокукына ия хатын-кызларны исәпкә алу реестрына кертелә, андагы чират җир кишәрлеген бирү турында гариза бирелү датасы һәм вакыты буенча билгеләнә.

9. «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызларга җир кишәрлекләре бирү чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

10. Җир кишәрлекләре шәһәр торак пунктлары чикләрендә кимендә 0,08 гектар һәм авыл торак пунктлары чикләрендә һәм башка категориядәге җирләрдә кимендә 0,25 гектар күләмендә бирелә.

11. Җирле үзидарә органнары җир кишәрлекләрен бирү нормаларын җир кишәрлекләренең җир законнары нигезендә билгеләнгән максималь чик күләмнәренә ярашлы рәвештә билгелиләр.

12. Вәкаләтле җирле үзидарә органы исәпкә куелган вакыттан алып 30 көн эчендә «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызга җир кишәрлеген бирү турында гаризада күрсәтелгән файдалану максатына туры килә торган җир кишәрлеген тәкъдим итә.

13. Җир кишәрлеген сайлау, җир кишәрлеген сайлаудан баш тарту «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кыз һәм вәкаләтле җирле үзидарә органы вәкиле тарафыннан имзалана торган акт белән рәсмиләштерелә.

14. Җир кишәрлеген сайлау актында җир кишәрлегенең кадастр номеры күрсәтелә, ә җир кишәрлеге «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кыз сайлаган вакытка төзелмәгән очракта, төзелергә тиешле җир кишәрлегенең урнашу урыны тасвирламасы күрсәтелә.

15. «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кыз сайлаган вакытка җир кишәрлеге төзелмәгән очракта, вәкаләтле җирле үзидарә органы җир кишәрлеген сайлау акты нигезендә тиешле җир кишәрлеген төзүне гамәлгә ашыра һәм аны дәүләт кадастр исәбенә алуны законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда гамәлгә ашыруны тәэмин итә.

16. «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кыз җир кишәрлеген сайлаудан баш тарткан очракта, вәкаләтле җирле үзидарә органы җир кишәрлеген сайлаудан баш тарту турындагы акт имзаланган көннән алып 30 көн эчендә «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызга бүтән җир кишәрлеген тәкъдим итә, ләкин ике тапкырдан да күбрәк түгел.

17. Җир кишәрлеген бирү турында вәкаләтле җирле үзидарә органы карары, «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кыз тарафыннан сайланган вакытка җир кишәрлеге төзелгән очракта, җир кишәрлеген сайлау акты имзаланган вакыттан алып 14 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә яисә, җир кишәрлеге «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кыз тарафыннан сайланган вакытка төзелмәгән очракта, җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә алуны гамәлгә ашырган вакыттан алып 14 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

18. Исәптән төшерү һәм җир кишәрлеген бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{19}$ статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген Россия Федерациясе Җир кодексының $39^{5}$ статьясындагы 6 һәм 7 пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча бер тапкыр милеккә түләүсез бирү

хокукының «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кыз тарафыннан гамәлгә ашырылуы;

2) «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кыз тарафыннан аны исәптән төшерү турында гариза тапшырылу;

3) «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызның Татарстан Республикасыннан читкә даими яшәү урынына китүе;

4) документларда күрсәтелгән һәм исәпкә кую турында карар кабул итү өчен нигез булган белешмәләргә туры килми торган белешмәләр ачыклану;

5) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылу;

6) «Герой ана» исеменнән мәхрүм ителү;

7) «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызның җир кишәрлеген сайлаудан өч тапкыр баш тартуы.

19. Исәптән төшерү һәм җир кишәрлеген бирүдән баш тарту өчен нигезнең булуы ачыкланган очракта, вәкаләтле җирле үзидарә органы исәптән төшерү һәм җир кишәрлеген бирүдән баш тарту турында карар нигез ачыкланган көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча кабул итә.

20. Исәптән төшерү һәм җир кишәрлеген бирүдән баш тарту турында карар «Герой ана» исеменә лаек булган хатын-кызга кабул ителгән көненнән алып җиде көн эчендә тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән җибәрелә йә аңа имза куйдырып тапшырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 25 июль
№ 52-ТРЗ